КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 август г.Казань № 717

2020 елга Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә норматив чыгымнарны һәм хезмәтләр күләмнәрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елга түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) раслагра:
Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә норматив чыгымнарны;
Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә хезмәтләр күләмнәрен.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә норматив чыгымнарны һәм хезмәтләр күләмнәрен раслау турында» 2018 ел, 1 сентябрь, 741 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.
3 Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 28 август, 717 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә норматив чыгымнар

| Хезмәт күрсәтү исеме | 1 кешегә норматив чыгымнар, сум |
|---|---|
| Ир-ат җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 1 497,38 |
| Ир-ат җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 1 605,79 |
| Яше 40 ка кадәр булган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 1 703,1 |
| Яше 40 тан арткан хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 1 811,51 |
| Яше 40 тан арткан маммография үтүче хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 1 948,79 |
| Яше 40 тан арткан маммография үтүче хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 2 057,2 |
| Яше 40 тан арткан маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 1 703,1 |
| Яше 40 тан арткан маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 1 811,51 |

_______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 28 август, 717 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы карамагындагы мәгариф оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә алдан, әледән-әле мәҗбүри медицина карауларын (тикшерүләрен) үткәрүгә хезмәтләр күләмнәре

| Хезмәт күрсәтү исеме | Саны, кеше |
|---|---|
| Ир-ат җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 20 247 |
| Ир-ат җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 756 |
| Яше 40 ка кадәр булган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 47 239 |
| Яше 40 тан арткан хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 1 764 |
| Яше 40 тан арткан маммография үтүче хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 44 541 |
| Яше 40 тан арткан маммография үтүче хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 1 663 |
| Яше 40 тан арткан, маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә әледән-әле медицина каравын үткәрү | 22 945 |
| Яше 40 тан арткан, маммография үтми торган хатын-кыз җенесендәге хезмәткәрләргә алдан медицина каравын үткәрү | 857 |

___________________________________